# Зөл Кәгъдә аеның үзенчәлекләре

## خصائص شهر ذي القعدة
## اللغة التترية

ALSARHAAN.COM

فضّل الله تعالى بعض الشهور على بعض.

**Аллаһ кайбер айларга башка айлардан өстенлек биргән.**

قال تعالى:

وَرَبُّكَ يَخۡلُقُ مَا يَشَآءُ وَيَخۡتَارُۗ

**Аллаһ әйтте:**

**«Һәм синең Раббың кемне тели барлыкка китерә, ә кемне тели сайлап ала».**

ومن الشهور التي فضلها الله تعالى شهر ذي القَعدة.

**Һәм шул айларның берсе – ул Зөл Кәгъдә ае.**

وهو الشهر الحادي عشر من شهور السنة الهجرية

**Һәм ул һиҗри елның унберенче ае.**

وسُمي بذلك لأن العرب قعدت فيه عن القتال تعظيما له واستعدادًا للحج في ذي الحجة.

**Гәрәпләрнең шушы айны хөрмәтләп анда сугыш тыюлары һәм шулай ук бу ай хаҗга әзерләнү ае булу сәбәпле ул нәкъ шулай исемләнгән.**

ومن خصائصه أنه بداية الأشهر الحرم

**һәм аның үзенчәлекләреннән – аның харам кылынган айларның беренчесе булып торуы.**

قال الله تعالى:

إِنَّ عِدَّةَ ٱلشُّهُورِ عِندَ ٱللَّهِ ٱثۡنَا عَشَرَ شَهۡرًا فِى كِتَٰبِ ٱللَّهِ يَوۡمَ خَلَقَ ٱلسَّمَٰوَٰتِ وَٱلۡأَرۡضَ مِنۡهَآ أَرۡبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ ٱلدِّينُ ٱلۡقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظۡلِمُواْ فِيهِنَّ أَنفُسَكُمۡ ۚ

**Аллаһ Раббыбыз әйтте:**

«**Аллаһ хозурындагы китапта айлар саны унике, җирне һәм күкләрне яраткан көннән бирле ул унике айның дүртесе сугыш хәрам булган айлар. Ошбу хөкемнәр туры дин, ул дүрт айда үзегезгә золымлык кылмагыз**».

وكانت العرب تحرمها لأمن الناس في سيرهم إلى الحج.

**Хаҗга таба юл тотучы кешеләр иминлектә булсыннар өчен, гәрәпләр бу айда сугышны тыйдылар.**

فجاء الاسلام وزاد من حرمتها وحرمة ابتداء القتال فيها.

**һәм Ислам дине килүе белән бу айның хәрам ае булуы һәм сугыш башлауны тыю тагын да арткан.**

والنهي عن الظلم فيها تعظيما لأمرها وتغليظا للذنوب فيها.

**һәм шулай ук шушы айда кылына торган гамәлләргә карата хөрмәт тарафыннан һәм гөнаһ кылуның җәзасы тагын да арттырылуы сәбәпле бу айда золымлык кылудан тыелу да арткан.**

وإن كان الظلم ممنوعا في غيرها.

**Ләкин золымлык кылу калган айларда да тыелган.**

ومن خصائصه أنه من أشهر الحج التي لا تنعقد نية الحج إلا فيها.

**һәм шулай ук бу айның үзенчәлекләреннән – аның хаҗ айларыннан булуы һәм анда гына хаҗ кылырга ният кылынуы.**

كما قال تعالى:

ٱلْحَجُّ أَشْهُرٌ مَّعْلُومَٰتٌ ۚ فَمَن فَرَضَ فِيهِنَّ ٱلْحَجَّ فَلَا رَفَثَ وَلَا فُسُوقَ وَلَا جِدَالَ فِى ٱلْحَجِّ ۗ

Раббыбыз әйтте:

«Хаҗ кылу мәгълүм булган айлар. Берәү хаҗ кылырга ниятен багласа, хаҗ гамәлләре тәмам булганчы якынлык кылу, шәригатькә хыйлаф булган эшләрне эшләү һәм низаглашу тыелган».

ومن خصائصه: أن النبي صلى الله عليه وسلم اعتمر فيه أربع عُمر

Һәм шулай ук бу айның үзенчәлекләреннән Пәйгамбәребезнең ﷺ шушы айда 4 тапкыр кече хаҗ ягъни гөмрә кылуы.

. فعن أنس رضي الله عنه أن النبي صلى الله عليه وسلم اعتمر أربع عُمر كلُهن في ذي القعدة إلا التي مع حجته.

Әнәстән )Аннан Аллаһ разый булсын( Пәйгамбәребез ﷺ дүрт тапкыр гөмрә кылганлыгы турында һәм алар, хаҗ белән бергә кылынган берсеннән башка, барысы да Зөл Кәгъдә аенда булганлыгы турында хәбәр ителә.

قال النووي: إنما اعتمر النبي صلى الله عليه وسلم هذه العمرة في ذي القعدة لفضيلة هذا الشهر ولمخالفة الجاهلية في ذلك.

**Имам ән-Нәвәви әйтте:**

**"Пәйгамбәребез ﷺ җәһеллеккә каршы тору һәм Зөл Кәгъдә аен хөрмәтләү өчен гөмрәне шушы айда башкарган.**

فإنهم كانوا يرون العمرة في الأشهر الحرم أفجر الفجور.

**Чынлыкта алар, ягъни җәһеллектә булган кешеләр, хәрам кылынган айларда гөмрә кылуны куркыныч гөнаһ дип исәпли торган булганнар.**